ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.05.2022 п.г.т.Алексеевское № 201

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлекләрен алып баручы, җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы, һәм җылылык челтәре оешмаларын 2022-2023 елга җылыту чорына әзерлеген Тикшерү буенча, комиссия турындагы Нигезләмәне раслау турында**

Инженерлык челтәрләрен, энергетика объектларын үз вакытында әзерләүне оештыру, җылылык белән тәэмин итү системаларының ышанычлылыгын киметүче җитешсезлекләрне бетерү,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлекләрен алып баручы, җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы һәм җылылык челтәрләре оешмаларының 2021-2022 еллар җылылык чорына әзерлеген бәяләү максатларында,«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җылылык белән тәэмин итү турында»2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законнары, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Җылылык тәэмин итү чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында»2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлекләрен алып баручы, җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы, һәм җылылык челтәре оешмаларын 2022-2023 елга җылыту чорына әзерлеген тикшерү буенча, комиссия турындагы Нигезләмәне расларга
(Кушымта № 1).

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлекләрен алып баручы, җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы , һәм җылылык челтәре оешмаларын 2022-2023 елга җылыту чорына әзерлеген тикшерү буенча, комиссия составын расларга ( Кушымта № 2).

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлекләрен алып баручы җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы,

һәм җылылык челтәрләре оешмаларының 2022-2023 еллар җылылык чорына әзерлеген тикшерү графигы нигезендә чараларны башкаруны оештырырга (Кушымта № 3).

4. 2022-2023 еллардагы җылыту чорына,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә , үз эшчәнлекләрен алып баручы, җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы , һәм җылылык челтәре оешмаларын 2022-2023 еллардагы җылыту чорына әзерлеген тикшерү программасын расларга (Кушымта № 4).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары М. Р. Гайсинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
31.05.2022 ел 201 нче карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлекләрен алып баручы, җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы, һәм җылылык челтәре оешмаларын 2022-2023 елга җылыту чорына әзерлеген тикшерү буенча, комиссия турындагы Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлеген алып баручы җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы һәм җылылык челтәрләре оешмаларының 2022-2023 еллар җылылык чорына әзерлеген тикшерү комиссиясе турында Нигезләмә җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы һәм җылылык челтәрләре оешмаларының җылылык чорына әзерлеген бәяләү комиссиясенең (алга таба – Комиссия) эш тәртибен билгели.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 12.03.2013 ел, № 103 «Җылылык чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» боерыгы, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, башка муниципаль хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Комиссиянең максатлары һәм бурычлары

2.1. Комиссия ягып җылыту чорында социаль өлкә һәм торак-коммуналь хуҗалык объектларының тотрыклы эшләвен тәэмин итү өчен төзелгән.

2.2. Комиссиянең төп бурычлары-җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларының җылылык чорына әзерлеген тикшерү.

## 3. Комиссия эшчәнлеген оештыру

3.1. Комиссия комиссия рәисе, Комиссия секретаре һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

3.2. Комиссия әгъзалары булып торалар:

-Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты вәкилләре;

-экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча Федераль хезмәт һәм торак инспекциясе вәкилләре килештерү буенча;

-җылылык белән тәэмин итүче оешмалар вәкилләре килештерү буенча.

3.3. Комиссия, халыкның коммуналь хезмәтләре белән тәэмин итүдә катнашучы милек формаларына бәйсез рәвештә, Комиссия эшенә предприятие, оешма, учреждениеләрнең вазыйфаи затларын җәлеп итәргә хокуклы.

3.4. Комиссия рәисенең төп функцияләренә түбәндәгеләр керә:

-Комиссия белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыру;

-Комиссия утырышларын билгеләү һәм көн тәртибен билгеләү;

-Комиссия утырышларында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыруга гомуми контрольне гамәлгә ашыру.

3.5. Комиссия утырышлары әзерлекне бәяләү һәм җылылык чорына әзерлек буенча нәтиҗәләр ясау буенча утырышларны үткәрү графигы нигезендә үткәрелә.

3.6. Комиссия секретаре:

-Комиссия утырышында карауга материаллар әзерләүне гамәлгә ашыра;

-Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

- Комиссия эше нәтиҗәләре турында документлар, беркетмәләр, актлар, әзерлек паспортлары әзерләүне гамәлгә ашыра.

## 4. Комиссиянең эш тәртибе

4.1. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кимендә ике атнага бер тапкыр уздырыла.

4.2. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

4.3. Комиссия әгъзасы җыелышта катнаша алмаган очракта, ул комиссиядә карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язмача тапшырырга яисә үз вәкилен алдан хәбәр итеп җибәрергә хокуклы.

4.4. Комиссия халыкны җылылык белән тәэмин итүдә катнашучы предприятиеләрдән, оешмалардан ,милек формасына карамыйча,Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматны соратып алырга хокуклы.

4.5. 2021-2022 елгы җылылык чорына әзерлекне тикшергәндә комиссия җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 12 март, 2013 ел, № 103 боерыгы белән расланган «Ягулык чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләре»нең III бүлегендә билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерә. Тикшерү үткәрү максатларында Комиссия әзерлек буенча таләпләрнең үтәлешен раслый торган документларны карый, ә кирәк булганда тикшерү объектларын карый.

4.6. Тикшерү нәтиҗәләре җылылык чорына әзерлекне тикшерү акты белән рәсмиләштерелә, ул тикшерү тәмамланганнан соң өч көннән дә соңга калмыйча төзелә. Комиссиянең әзерлек таләпләрен үтәүгә карата кисәтүләре булган яки актка әзерлек таләпләрен үтәмәгән очракта, аларны бетерү срокларын күрсәтеп, кисәтүләр исемлеге бирелә.

4.7. Һәр объект буенча, актка кул куелганнан соң, 15 көн эчендә, әгәр объект җылыту чорына әзер булса, шулай ук комиссия тарафыннан бирелгән әзерлек таләпләренә карата кисәтүләр вакытында бетерелгән очракта, ягып җылыту чорына әзерлек паспорты бирелә.

4.8. Комиссия карары комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
31.05.2022 ел 201 нче карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлекләрен алып баручы, җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы, һәм җылылык челтәре оешмаларын 2022-2023 елга җылыту чорына әзерлеген тикшерү буенча, комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Гайнуллин О.А. | - Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Гайсин М.Р. | - Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары. |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Леденцов Н.И. | - «Инженерлык челтәрләре» ҖЧҖ генераль директоры (килештерү буенча); |
| Зиганшин Р.Р. | - Алексеевск район эксплуатацион газ хезмәте җитәкчесе (килештерү буенча); |
| Хабибуллин И.И. | - Идел буе гомуми сәнәгать һәм дәүләт энергетика күзәтчелеге бүлеге башлыгы (килештерү буенча); |
| Шамсутдинов И.М. | - Идел буе гомум сәнәгать һәм дәүләт энергетика күзәтчелеге бүлеге дәүләт инспекторы (килештерү буенча); |
| Крюков С.А. | Идел буе гомум сәнәгать һәм дәүләт энергетика күзәтчелеге бүлеге дәүләт инспекторы (килештерү буенча); |
| Сабиров И.А. | Идел буе гомум сәнәгать һәм дәүләт энергетика күзәтчелеге бүлеге дәүләт инспекторы (килештерү буенча); |

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
Районы Башкарма комитетының
31.05.2022 ел 201 нче карарына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлекләрен алып баручы җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы, һәм җылылык челтәрләре оешмаларының 2022-2023 еллар җылылык чорына әзерлеген тикшерү графигы**

| Тикшерелергә тиешле оешма | Тикшерү вакыты |
|---|---|
| ҖЧҖ «Инженерные сети» | 01. 09. 2022 кадәр |

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.А. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
31.05.2022 ел 201 нче карарына
4 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә , үз эшчәнлекләрен алып баручы, җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы , һәм җылылык челтәре оешмаларын 2022-2023 еллардагы җылыту чорына әзерлеген тикшерү программасы**

## Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә, үз эшчәнлекләрен алып баручы, җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы, һәм җылылык челтәре оешмаларын 2022-2023 еллардагы җылыту чорына әзерлеген тикшерү буенча әлеге программа (алга таба-программа) - «Җылылык белән тәэмин итү турында» 27 июль, 2010 ел, № 190-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 12 март, 2013 ел, № 103 боерыгы, Федераль экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге хезмәтенең «Муниципаль берәмлекләрнең җылылык чорына әзерлеген тикшерү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында» 17 июль, 2013 ел, № 314 боерыгы нигезендә эшләнгән.

## Контрольгә алынырга тиешле мәсьәләләр исемлеге

Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларының 2022-2023 еллар җылылык чорына әзерлеген бәяләгәндә комиссия тарафыннан түбәндәге сораулар тикшерелә:

1.«Җылылык белән тәэмин итү турында»2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә төзелгән җылылык белән тәэмин итү системасы белән идарә итү турында килешү булу;

2. Җылылык йөкләнешенең графигын үтәргә, җылылык белән тәэмин итү схемасы белән расланган температура графигын саклап калырга әзер булу;

3.Җылылык белән тәэмин итүнең техник регламентларда билгеләнгән ышанычлылык критерийларын үтәү;

4.Җылылык энергиясе чыганакларында норматив ягулык запаслары булу;

5.Эксплуатацион, диспетчерлык һәм авария-торгызу хезмәтләре эшчәнлеге, атап әйткәндә:

- күрсәтелгән хезмәтләрнең персонал белән комплектлануы;
- персоналны шәхси һәм коллектив саклау чаралары, махсус киемнәр, эшләр башкару өчен кирәкле инструментлар,кирәк яраклар, норматив-техник һәм оператив документлар, инструкцияләр, схемалар, беренчел янгын сүндерү чаралары белән тәэмин итү;

6. Алар карамагындагы җылылык челтәрләрен җайга салу;
7.Җылылык энергиясен куллану режимнарын контрольдә тотуны оештыру;
8.Җылылык тапшыргычларның сыйфатын тәэмин итү;
9.Сатып алына торган һәм сатыла торган җылылык энергиясенең коммерцияле учетын оештыру;
10.«Җылылык белән тәэмин итү турында»2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, төзелештә кулланыла торган эшләргә һәм материалларга гарантияләр бирү, аларга караган җылылык челтәрләрен төзүнең сыйфатын тикшерүне тәэмин итү;
11.Җылылык белән тәэмин итү объектларының авариясез эшләвен һәм җылылык энергиясен кулланучыларны җылы белән тәэмин итү, аеруча:
-ягулык кабул итү һәм бушату, ягулык әзерләү һәм ягулык бирү системаларының әзерлеге;
-су-химия режимын үтәү;
-җылылык-энергетика җиһазларын эксплуатацияләү вакытын озайту буенча тиешле оештыру-техник чаралар үткәрмичә генә файдалану фактларының булмавы;
-җылылык чыганакларының җылылык егәрлегенә кытлык булганда җылылык белән тәэмин итүне һәм җылылык челтәрләренең үткәрүчәнлек сәләтен чикләүнең расланган графиклары булу;
-торак йортларны җылылык белән тәэмин итү буенча авария хәлендәге җитешсезлекләрне бетерүнең рөхсәт ителгән вакытының исәпләре булу;
-җылылык, электр, ягулык һәм су белән тәэмин итү оешмаларының, җылылык энергиясен кулланучыларның, ремонт-төзелеш һәм транспорт оешмаларының, шулай ук җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген исәпкә алып, җылылык белән тәэмин итү системаларында авария хәлләрен бетерү тәртибенең булуы;
-җылылык челтәрләрен гидравлик һәм җылылык сынаулары үткәрү;
-җылылык белән тәэмин итүдә катнашучы җиһазларны тиешле техник тикшерү һәм диагностикалау үткәрү кертелгән җылылык бирү чорына эшкә әзерлекнең расланган планын үтәү;
-җылылык челтәрләрен һәм җылылык энергиясе чыганакларын ремонтлау буенча план графигын үтәү;
-ягулык белән тәэмин итү килешүләренең ягулык запасларының билгеләнгән нормативларын киметүгә юл куймый торган булуы;
12.Җылылык энергиясен кулланучылар, җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары арасында эксплуатация җаваплылыгын чикләүне билгели торган документлар булу;
13.Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан бирелгән җылылык чорында эшнең ышанычлылыгына йогынты ясый торган билгеләнгән срокларда үтәлмәгән күрсәтмәләрнең булмавы;
14. Булганда,автоматик җайга салучыларның эшләве.

**Тикшерелергә тиешле объектлар**

1. «Инженерлык челтәрләре»ҖЧҖ;

2. Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районы чикләрендә урнашкан җылылык челтәрләре.

Тикшерү үткәрү вакыты: 2022 елның 1 сентябренә кадәр.

**Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү**

Тикшерү үткәрү буенча эш нәтиҗәләре әлеге Программа нигезендә Комиссиянең тикшерү акты белән рәсмиләштерелә. Мәгълүмат электрон рәвештә, шулай ук кәгазьдә тапшырылырга тиеш. Гомумиләштерелгәннән соң тикшерү актының беренче нөсхәсе һәм күрсәтмә (ачыкланган бозулар булганда) оешма җитәкчесенә – җылылык энергиясен кулланучыга тапшырыла, икенчесе – тикшерү үткәрү өчен җаваплы затта кала. Тикшерү нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, тикшерелүче оешма – җылылык энергиясен кулланучылар вәкилләре, күрсәтмәдә үз фикерләрен чагылдырырга хокуклы.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.А.Йосыпова**